ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**10.07.2020**

Зеленодольск шәһәре

**КАРАР**
**№ 1259**

Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2013 елның 15 мартындагы 413 номерлы карары белән расланган (Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2015 елның 18 февралендәге 323 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләр белән) Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасына керүче зат, шулай ук Зеленодольск муниципаль районы муниципаль учреждениесе җитәкчесе тарафыннан керемнәр, милек һәм милек характерындагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Хезмәт Кодексының 275 статьясы, Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты,

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2013 елның 15 мартындагы 413 номерлы карары белән расланган (Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2015 елның 18 февралендәге 323 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләр белән) Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасына керүче зат, шулай ук Зеленодольск муниципаль районы муниципаль учреждениесе җитәкчесе тарафыннан керемнәр, милек һәм милек характерындагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

– 2 пунктның өченче абзацында «ел саен, хисап чорыннан соң килүче елның 30 апреленнән дә соңга калмыйча» сүзләрен «ел саен, Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат бирү өчен билгеләнгән срокларда»сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны Зеленодольск муниципаль районы Советы Аппаратының җәмәгатьчелек һәм ММЧ белән элемтә бүлеге начальнигы Р.З.Хаҗиевка «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмат сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә .

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшерүне торуны Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары А.В. Старостинга йөкләргә.

Зеленодольск муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе М.П. Афанасьев